**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ**
**Старосляковского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Иске Эсләк авыл җирлеге**
**СОВЕТЫ**

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29.12.2018 Иске Эсләк авылы № 47-5

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иске Эсләк авыл җирлеге Советының «Физик затларның милкенә салым турында»гы 2014 елның 14 ноябрендәге 21-2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлеге Советы карар бирде:

1.Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иске Эсләк авыл җирлеге Советының «Физик затларның милкенә салым турында»гы 2014 елның 14 ноябрендәге 21-2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1) 0,1 процент итеп түбәндәгеләргә:

гаражлар һәм машина кую урыннары, шул исәптән салым салу объектларында урнашкан, әлеге карарның 4.1 пунктында күрсәтелгән;

аларның һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, дача хуҗалыгы, яшелчәчелек, бакчачылык яки шәхси торак төзелеше өчен бирелгән җир өлешләрендә урнашкан хуҗалык корылмалары яки корылмаларга;»

2) 0,2 процент итеп түбәндәгеләргә:

"фатирлар, фатир өлешләренә;

бүлмәләргә;»

3) 0,3 процент итеп түбәндәгеләргә:

«торак йортлар, торак йортларның өлешләренә;

төзелеп бетмәгән объектларга, әгәр мондый объектлар торак йорт итеп проектланган булса;

составына бер булса да торак йорт керүче бердәм күчемсез комплексларга;

4) 2 процент итеп түбәндәгеләргә:

Россия Федерациясе Салым кодексының 7 пунктындагы 378 мәддә нигезендә ачыкланучы исемлеккә кертелгән салым салу объектларына;

һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән һәр салым салу объектларына;

5) 0,5 процент күләмендә башка салым салу объектларына.

1.2. 2 пунктны 2.1-2.2 пунктлары белән тулыландырырга.

2.1. Физик затлар милкенә салым түләүдән азат итәргә:

2.1.1. 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнарны;

2.1.2. 3.1.1. пунктында күрсәтелгән гражданнарның балалары.

2.2. Салым ташламасы салым салу объектларының түбәндәге төрләренә карата бирелә:

1) фатирлар, фатир өлешләре, бүлмә, торак йорт, торак йортның өлешләренә;

2) гараж яки машина кую урыны;

3) төзелеп бетмәгән объектларга, әгәр мондый объектлар торак йорт итеп проектланган булса;

4) составына бер булса да торак йорт керүче бердәм күчемсез комплексларга;»

5) аларның һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, дача хуҗалыгы, яшелчәчелек, бакчачылык яки шәхси торак төзелеше өчен бирелгән җир өлешләрендә урнашкан хуҗалык корылмалары яки корылмаларга;».

Салым ташламасы, салым түләүче сайлавы буенча салым ташламаларын куллану нигезләренең күләменә карамастан, гаиләгә туры килә торган һәр төр салым салуның бер объектына карата бирелә.

Салым ташламасы салым түләүчеләргә салым түләүче милкендә булган һәм эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган салым салу объектына карата түләнергә тиешле күләмдә бирелә.

Салым ташламасы хокукына ия физик зат салым органына ташламалар бирү турында гариза һәм салым ташламасына хокукын раслаучы документлар тапшыра.

Салым ташламасы бирелә торган объектлар турында хәбәрнамәне салым түләүче салым чоры булып торган елның 1 ноябренә кадәр салым органына тапшыра, аннан башлап күрсәтелгән объектларга карата салым ташламасы кулланыла»

2.Үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иске Эсләк авыл җирлеге Советының “Физик затларның милкенә салым турында” 2018 елның 18 июлендәге 39-1 санлы карарының 2 пункты.

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иске Эсләк авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иске Эсләк авыл җирлеге Советының 2018 елның 16 ноябрендәге «Физик затларның милкенә салым турында»гы 45-2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында” карары.

3. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Иске Эсләк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына куярга, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтына agryz.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталына pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

5. Әлеге Карарны үтәүгә контрольне үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
авыл җирлеге Башлыгы И.Н. Гафаров